Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге
Урта Ия торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

28 ноябрь, 2021 ел . № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең Урта Ия торак пунктында 2021 елның 28 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 17 (ун җиде).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 10 (ун).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 10 (ун).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча « Сез 2022 елда Урта Ия торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов